**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 9 июнь № 374

г. Казань

Татарстан Республикасының «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләренең автоматлаштырылган мәгълүмат системасы» дәүләт мәгълүмат системасы турында нигезләмәне раслау хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 ел, 22 декабрь, 1376 нчы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә электрон рәвештә, шул исәптән универсаль электрон карталарны файдаланып, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 ел, 28 октябрь, 864 нче карары нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләренең автоматлаштырылган мәгълүмат системасын эксплуатацияләүне һәм үстерүне тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлгән Татарстан Республикасының «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләренең автоматлаштырылган мәгълүмат системасы» дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба – Система) турында нигезләмәне расларга.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгын – Системаның дәүләт заказчысы итеп;

«Татарстан Республикасының мәгълүмат технологияләр үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесен – Системаның техник операторы итеп, аңарга Системаны булдыру, үстерү һәм техник ярдәм күрсәтү, шулай ук Системада эшкәртелгән мәгълүматны техник саклау буенча чаралар үткәрүне тәэмин итү вәкаләтләрен биреп;

«Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесен – Системаның функциональ операторы итеп, аңарга Системаның шәхси мәгълүматлары операторы вәкаләтләрен биреп.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков